**“2022 нче елга тәрбия-белем бирү эшчәнлегенә анализ”**

Тәрбия-белем бирү процессы төп белем бирү программасын камилләштереп, мәктәпкәчә белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларына таянып, Н.Е. Вераксаның, Т.С. Комарованың һәм М.А. Васильеваның “Туганнан алып мәктәпкәчә” үрнәк программасы нигезендә эшләнде. (Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева «Примерная основная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы»», Москва, 2015.)

Шулай ук еллык план, Сан Пин нормаларына туры китереп төп белем бирү эшчәнлеге челтәре, көндәлек режим, календарь планнар, педагогик киңәшмәләрдә каралып, мөдир Хайдарова Рәзинә Госмановна тарафыннан расланып, тәрбия-белем бирү процессында уңышлы гына кулланыла. Тәрбиячеләр тарафыннан эш программалары, комплекс-тематик планнар төзелгән. Атна саен тәрбия-белем бирү планнары төзелә, планнар өлкән тәрбияче тарафыннан тикшерелеп, шуның буенча төркемнәрдә тәрбия- белем бирү эшчәнлекләренең барлык төрләре оештырыла. Балалар бакчасының уңышлы эшчәнлеге өчен оптималь шартлар тудырылган. Балалар бакчасында тәрбия-белем бирү процессы мәктәпкәчә белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларына, белем бирү өлкәләренең интеграция принципларына туры китереп, балаларның мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен күз алдында тотып нигезендә уен эшчәнлеген алгы планга куеп, комплекс-тематик план ярдәмендә оештырылган принциплар тора.

**СЛАЙД №2**

Балалар бакчасында 18 педагог эшли. **Шулар арасыннан:**
13– югары белемле /79%/
5 - махсус урта белемгә ия /21%/
2- югары уку йортларында укыйлар /10%/

Слайдта балалар бакчасында эшләүче педагоглар буенча өч елга анлизны күреп китәргә була.

**СЛАЙД №3**

Югары белемле педагогларның саны елдан-ел ким, чөнки без урта махсус уку йортларын бетергән тәрбиячеләрне эшкә алабыз. Аларга үсәргә мөмкинлек бирәбез. Куелган максат педагогларның белем дәрәҗәсе һәм сыйфаты даими үсүне, үз өстендә системалы эшләүне таләп итә.

**СЛАЙД №4**

**Педагогларның квалификацион дәрәҗәләре:**

| | Всего педагогов | I категория | Высшая категория | Всего с категорией |
|---|---|---|---|---|
| **2020** | 19 | 10 | 5 | 15 |
| **2021** | 19 | 12 | 4 | 16 |
| **2022** | 18 | 12 | 3 | 15 |

Диаграммадан күренгәнчә, категорияларның саны кимеде, аның сәбәпләре:
- 2020 нче елда югары категорияле Гиндуллина Г.Х. 76 нчы балалар бакчасына китте,

аннан соң Гимадеева Н.Х., Камалетдинова А.И., 1 нче категорияле тәрбиячеләр 87 нче бакчага күчтеләр.

-2021 нче елда югары квалификацион категорияле Шигапова З.Ф. 11 нче бакчага, беренче квалификацион категорияле педагог Иванова А.Р. 89 нчы балалар бакчасына күчте, ә алар урынына категориялы булмаган тәрбячеләр килде. Бер педагог декрет ялында.

**СЛАЙД №5**

2022 нче уку елында бер педагог (Самиева М.Д.) беренче категориясен раслады, бер педагог югары квалификацион категориясен (Архипова В.А.,) , бер педагог (Имамова Л.П.) беренче категорияне алды.ия булдылар.

Югары категорияларның саны 2020 нче ел белән чагыштырганда ким.

**СЛАЙД№6**

3 педагогның эш стажлары әле аз булганлыктан категориялары юк.

**СЛАЙД№7**

Үз белемнәрен күтәрү темасы буенча системалы эш алып барыла. Методик бүлмәдә информацион стендта перспектив план төзеп куелды.

Перспектив план буенча 4 педагог электрон белем бирү программасы аша гариза биреп, МОиНРТ тарафыннан оештырылган бюджет курслары үттеләр.

*4 педагогов прошли курсы повышении квалификации*

-Самиева Мунзиля Давлетовна
(ГАПОУ «Нижнекамский педагогический колледж»)
-Бадертдинова Резеда Раисовна
(ГАПОУ «Нижнекамский педагогический колледж»)
-Садыкова Венера Эльвардовна
(Казанский инновационный университет имени В.Г. Тимирясова)
- Имамова Лиана Петровна
(ГАПОУ «Набережночелнинский педагогический колледж»)

**СЛАЙД№8**

Педагогларның педагогик эш стажларына килгәндә, өч елга кадәрле педагогларның һәм шулай ук 20 елдан артык стажлы педагогларның артуы күренә.

**СЛАЙД №9**

Ә менә бу слайдта балалар бакчасында яшь буенча нинди педагоглар эшләве күренә

Гомумән алганда, бүгенге көндә тупланган педагогик коллектив тырыш, иҗади оешкан, белемгә омтылышлы коллектив булып формалашты.

Һәр педагог үзенә үз белемен күтәрү темасын сайлый, ел барышында шул тема астында әдәбият туплап, ачык эшчәнлекләргә, методик берләшмәләргә, семинарларга даими йөри, үзенең темасын һәрьяклап тормышка ашыра, әти-әниләр өчен консультаөиялар туплый, ачык эшчәнлекләр күрсәтә, төрле шәһәркүләм чараларда тәҗрибә белән уртаклашалар.

**СЛАЙД 10,11**

Балалар бакчасында тәрбия-белем бирү процессы үсеш һәм белем бирү программасы нигезендә оештырыла.

2022 нче уку елында куелган бурычлар һәрьяклап чишелде. Педагоггик киңәшмәләр, мастер-класслар, семинар-практикумнар, методик берләшмәләр оештырылды.

Тәрбия - белем бирүдә педагоглар программаның барлык юнәлешләрен (социаль-коммуникатив, сөйләм үстерү, танып белү, нәфис-нәфасәти үсеш, физик үсеш) гамәлгә ашыру өчен бөтен көчләрен куйдылар.

Педагогик киңәшмәләрдә балаларның физик, психик, социаль, сөйләм үсешенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр һәм кече яшьтәге балаларның бакчага ияләшү соруалары, физик сәламәтләндерү эшләрен һәм халык традицияләренә, милли гореф-гадәтләренә нигезләнеп, әхлакый хисләр тәрбияләүне оештырулар, ФДББС таләпләренә туры китереп тәрбия-белем бирү эшен яңартулар каралды.

**СЛАЙД 12**

24 нче ноябрьдә аенда "Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда театр эшчәнлеге аша Рәсәй халкы мәдәниятенә һәм милли традицияләренә кызыксыну формалаштыру" исемле зональ семинар-пратикум уздырылды. Бу семинарга Алабуга, Чаллы, Зәй, Чистай, Түбән Кама һ.б шәһәрләрдән педагоглар катнашты. Ковид чикләүләре аркасында соңгы ике елда чаралар читтән торып үткәрелсә, безнең семинарга 4 бакчадан тәрбиячеләр килгән иде. Калган педагоглар үз эшләрен ВКонтакте челтәрендә урнаштырдылар. : нчы төркем балалары белән "Халкым мирасы" музеена экскурсия үткәрелде, 5 нче төркем балалары катнашында "Чуар тавык" әкияте сәхнәләштерелде, Архипова В.А. сәйлән үрү серләренә төшендерде. Килгән педагогларның чыгышлары тыңланды.

Шулай ук май аенда "Җиңү кайтавазы" исеме астында зонакүләм бәйге уздыАнда иң яхшы бәйрәм сценарияләре авторлары, иң яхшы проект авторлары ачыкланды. Бу чарага мәртәбәле кунаклар, жюри әгъзалары килде. Бәйге уен – җыр, мастер – класслар белән үрелеп барды.

**СЛАЙД №16**

2022 нче елның май аеннан без "Рухи – әхлакый тәрбия бирү" темасы буенча федераль күләмдә инновацион мәйданчык исеменә лаек булдык. Бик зур эш алып барылды.

**СЛАЙД №17**

2017 нче елда халыкара "Эко-школа/Зеленый флаг" программма белән эшли башладык. Быел 5 нче флагыбызны алдык. Санкт-Петербург шәһәрендәге "Санкт-Петербург за экологию Балтики" оешмасы белән договор төзедек. 2017 нче елдан башлап "Кәгазь" темасын алып, шул тема астында план төзелде. Һәм шул план буенча төрле чаралар оештырыла. Яңа елда кәгазьдән елкалар ясап, күргәзмәләр оештырылды. "Мобэко" оешмасына макулатура җыеп тапшырдык. Барлык төркемнәрдә "Тылсымлы кәгазь" темасы буенча проект эшләре алып баралар.Бу эштә Архипова В.А., Саметова Р.И. зур эш алып баралар.

**СЛАЙД 18,19, 20**

**Федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыру шартларында балалар бакчасы һәм мәктәп эшчәнлеге барышында дәвамчанлык.**

Балаларның мәктәптәге өлгерешләре аларның балалар бакчасында алган белем-тәрбияләренә нигезләнә. Федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыруның максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: балалар бакчасы һәм мәктәп арасында дәвамчанлык урнаштыру, ә бу үз чиратында балаларның бакчадан китеп, мәктәпкә җиңел кереп китүләренә ярдәм итә; һәр балага үз мөмкинлекләрен тулаем ачарга булышу; балаларны мәктәп белән кызыксындыру, мәктәпкә барасы килү теләген үстерү.

Безнең балалар бакчасы белән шәһәребезнең 7 нче мәктәп арасында ныклы элемтә урнашкан. Ел башында мәктәп һәм балалар бакчасы арасында дәвамчанлык планы төзелә. План педколлектив киңәшмәсендә тикшерелә һәм кабул ителә. Киңәшмәләрдә шулай ук коллектив алдында торган бурычлар тикшерелә, эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясала. Методик эш план буенча алып барыла.

Без үзебез, мәктәпкә әзерлек төркеме белән мәктәпләргә барабыз, дәресләр карыйбыз, укучылар һәм укытучылар белән очрашабыз. Балаларда укуга кызыксынучан караш уятабыз. Шулай ук 1 сыйныфта укыган балаларның “ачык дәресләрендә”катнашабыз.

Шушы барлык эшләр нәтиҗәсендә безнең бакча балалары мәктәпкә ныклы әзерлек белән китәләр, балалар бакчасыннан мәктәпкә күчүдә авырлык сизмичә, уңышлы гына укып китәләр. Бу эшләребезнең нәтиҗәсе булып, 7 нче мәктәпнең мактау тактасында безнең балаларыбызның да булуы безнең өчен бик зур шатлык.

2022 нче елда 42 бала мәктәпкә китте. 9 бала татар классларында укый.

**СЛАЙД №21**

Тәрбия һәм өйрәтү эшенең системалы баруын, балаларга сыйфатлы белем бирүне күзәтү максатыннан тәрбиячеләр йомгаклау буенча белем бирү эшчәнлекләрен күрсәттеләр.Үткәргән белем бирү эшчәнлекләре ФДББСга нигезләнеп, дөрес методик таләпләргә туры килеп үтте.

**СЛАЙД 22,23,24**

Ел дәвамында педагогларыбыз төрле дәрәҗәләрдә үткәрелгән семинарларда һәм педагогик конференцияларда эш тәҗрибәләре белән уртаклашып торды.

Шәһәр күләмендә, региональ семинарларда бакчабыз педагоглары шулай ук актив булдылар. Шулай ук конкурсларда актив катнашалар.

Иң актив педагогларны слайдта күреп китә алабыз.

Педагогларның конкурста катнашкан нәтиҗәләре

2023 нче елда барлык педагогларга да конкурсларда актив катнашуны максат итеп куябыз.

**СЛАЙД №25**

**<u>Достижение воспитанников</u>**

Балалар шәһәр, район, республика, Россия күләмендә оештырылган шәһәр күләмендә уздырылган балалар өчен оештырылган олимпиадаларда, төрле конкурсларда ел дәвамында һәрвакыт катнашып килделәр.

“Мин татар малае” (Алабуга), “Мин Тукай варисы”, “Сөйкемле бала” (Хуснутдинов Азат), “Этих дней не смолкнет слава” (Алабуга) (Даулетов Алмаз), китапханәдә һәрвакыт шушы балалар белән чыгыш ясадык, балалар фестивалена актив катнаштык, шулай ук хәзерге икенче төркем (зурлар төркеме), уртанчылар төркеменә зур өметләр баглыйбыз.

Кечкенә төркемнәргә килгәндә, 7 нче төркем (балалары кечкенә) азаккы урында булса да, тәрбияче үзе актив катнаша.

Слайд карап үтелә, кайсы группа ничәнче урында.

Башка чараларга килгәндә, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның багышланган иҗат кичәләрендә актив катнашабыз. “Дәү әнидә кунакта” музыкаль – әдәби чара бик яхшы узды.

Ел барышында федераль дәүләт белем бирү стандартларын күзалдында тотып “Муса Җәлил-балалар дусты”, “Өлкәннәр көне”, “Ветераннарның батырлыгы мәңгелек” бәйрәме, “Төсле бантиклар”, “Масленица” күңел ачу кичәләрен бигрәк тә уңышлы узуын әйтеп үтәсе килә.

Үзәк коридорда, төркемнәрдә мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән таныштыру максатыннан стендлар тулыландырып торыла. Алар даими рәвештә алышынып торды. Әти-әниләр өчен, педагоглар өчен консультацияләр ясалды.

Барлык төркемнәрдә эшчәнлекне оештыру буенча материаль – техник база баетылды, әдәбият тупланды, тематик планнар төзелде, материал ломинатланды. Һәрбер педагог белән план

нигезендә индивидуаль эш алып барылды, методик сәгатьләр, киңәшмәләр, әңгәмәләр оештырылды.

Шулай ук һәрбер төркемдә балаларга юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнүгә бик зур игътибар бирелде. Тормыш куркынычсызлыгы почмакларында юл йөрү кагыйдәләре темалары һәрвакыт алышынып, яңартылып торды.

Әти-әниләр белән эш алып барылды. Ноябрь аенда “Әниләрне хөрмәтләү көне”, октябрь аенда “Өлкәннәр көне”, 23 нче февральда “Әйдәгез, ярышыйк” исеме астында күңел ачу кичәләре үтте. Әтиләр һәм әниләрнең активлыгы, эш төрләренең байлылыгы, чараларның иҗади, тирән узуына китерде. Әти-әниләр һәм килгән кунаклар рухи күтәренкелек белән таралыштылар.

Бары тик “Балалар-гаилә”принцибы белән бергәләп алып барылган эш кенә тәрбия-белем бирү эшчәнлегендә уңай нәтиҗәләр бирә. Бергәләп башкарылган чаралар турында фото стендларда, белдерүләрдә, ачык ишекләр көннәрендә, балалар бакчасы сайтында яктыртылып килде. Гомумән, ата-аналар белән тыгыз эш алып барылды һәм ул системага салынды. Алар өчен медицина, ел фасыллары, сезонлы күзәтүләр, балалар хокукларын яклау буенча һәрдаим консультацияләр төзелде, бигрәк тә юл йөрү кагыйдәләрен пропагандалау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше эшенә, темасына аерым игътибар ителде: махсус почмаклар, ширмалар төзелде.

Балалар бакчасында әти-әниләр белән эш төрле формаларда алып барылды: анкеталар үткәрелде, актуаль темаларга консультацияләр бирелде, стенлардагы мәгълүматлар тулыландырылды, ачык ишекләр көне, бердәм бәйрәмнәр күңел ачулар үткәрелде. Әти-әниләр белән бергә 2 гомуми җыелыш үткәрелде. Квартал саен әти-әниләр өчен төркемнәрдә балалар белән турыдан туры белем эшчәнлеген күрсәтеп җыелышлар үткәрелде. Әти-әниләр актив катнашты.

**Җәмгыять оешмалары белән эш**

Тәрбия -белем бирү процессын тагын да тулырак алып бару өчен төрле җәмгыять оешмалары белән килешүләр төзелде һәм иҗади эш нәтиҗәләре ачыкланды. Түбән Кама, Яр чаллы, Әлмәт курчак театрлары, 7 нче урта мәктәп, , экология һәм биология үзәге, экскурсия һәм туризм оешмасы, ЮХИДИ, Түбән Кама татар дәүләт театры, 38 нче балалар китапханәсе, “Заман” уку һәм аралашу үзәге, Халыклар дуслыгы йорты белән тыгыз эш оештырылып алып барылды.

Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр куллану кирәклеген белеп, балаларга тәрбия-белем бирү эшен үз югарылыгында оештырылды.

Балаларның сөйләм үсешен камилләштерүдә яңа технологияләр, эш алымнары, программалар куллану, тәҗрибә эшен яшь үзенчәлекләренә туры китереп үткәрү, аны халык педагогикасы, сөйләм үстерү, мәктәпкә хәзерлек белән бәйләү юлларын ачу үзенчәлекләрен үз эченә алган педагогик киңәшмәләр презентацияләр, эшлекле уеннар, күргәзмәләр ярдәмендә аңлаешлы, үтемле итеп үткәрелде.

Нинди генә чаралар үткәрсәк тә, югары бәяләнсәк тә, баларның сөйләмен үстерү, аны формалаштыру, камилләштерү безнең төп бурычыбыз булып кала. Күзәтүләрдән чыгып без балаларның сөйләмен тиешле дәрәҗәгә куярга, аның сыйфатын яхшыртырга, программа таләпләрен үтәргә һәм иҗади, системалы эш алып барарга тиешбез. Монда беренче шарт булып үзебезнең үрнәк сөйләмебез тора. Аның өстендә эшләргә, ачык шогыльләргә йөрергә, ә үз белемеңне күтәрүгә игътибар итәргә кирәк.

2023 нче елда үзебезнең белемебез өстендә даими эшләргә, тәҗрибә белән уртаклашуны дәвам итәргә, Республика, зональ конкурсларда катнашуның дәрәҗәсен арттырырга, эксперименталь-инновацион эшчәнлектә, социаль-шәхси үсеш юнәлеше буенча яңа технологиялар кулланып, милли традицияләрне гамәлгә кертеп, фәнни җитәкчелек нигезендә планлы эшне дәвам итәргә, халыкара “Эко-школа/Зеленый флаг” программасы нигезендә иҗади эш алып барырга, тәрбия-белем бирү процессын нәтиҗәле итеп оештырырга. Балаларның тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү, балаларның сөйләмен, уен эшчәнлеген үстерүне бакча-гаилә-мәктәп принцибы белән, яңа технологияләр ярдәмендә системалы эшләүне максат итеп алабыз.

Алда торган бурычларны тормышка ашыра барып актуаль проблемаларны читтә калдырмаска, үзебезнең белемебез өстендә даими эшләргә, тәҗрибә белән уртаклашырга, традицион булмаган методлардан файдаланырга, балаларны мәктәпләргә әзерлекле итеп, җәмгыятькә яраклы шәхес булып үсүләренә ирешергә, иҗади эшләргә, тәрбия бирүдә халык педагогикасыннан киң файдаланырга чакырабыз.

.